| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ |

№ ___702/о_______

П Р И К А З　　　　　　　　　　　　　　　　　　Б О Е Р Ы К

«___02__»_______06_______2025__

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгын боерыгына үзгәреш кертү турында

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Теплогазпроект» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 25.04.2025 ел, № 2932 мөрәҗәгате белән бәйле рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, «Минзәлә урманчылыгы» ДКУ чикләрендә урнашкан линия объектларын төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү» линия объектларын урнаштыруны күздә тоткан территорияләрне ызанлау проектын раслау турында» 2025 елның 21 мартындагы 319/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, «Минзәлә урманчылыгы» ДКУ чикләрендә урнашкан линия объектларын төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү» линия объектларын урнаштыруны күздә тоткан территорияләрне ызанлау проектының 2 бүлегенә үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә бирергә (кушымтада).

2. Территорияләрне үстерү департаментының агломерацияләрне үстерү идарәсенең төньяк-көнчыгыш районнарны үстерү бүлегенә (Н.Г.Елагинага) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә ул үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрүне;

әлеге боерыкны үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

әлеге боерыкны «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында ул басылып чыккан көннән алып 10 эш көне эчендә урнаштыруны.

3. Юридик бүлеккә (Р.И.Кузьминга), дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Территорияләрне үстерү департаментының Агломерацияләрне үстерү идарәсе башлыгы С.А.Рыбаковка йөкләргә.

Министр урынбасары В.Н. Кудряшев

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм
торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгының
02.06.2025 ел, № 702/о__
боерыгы белән расланды

# Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, «Минзәлә урманчылыгы» ДКУ адресы буенча урнашкан «Линия объектларын төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү» линия объектларын урнаштыруны күздә тоткан территорияне ызанлау проекты

Теплогазпроект
ОБЩЕСТВО С ОГРАНИЧЕННОЙ ОТВЕТСТВЕННОСТЬЮ

**Заказчы – В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ**

**Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, «Минзәлә урманчылыгы» ДКУ адресы буенча урнашкан «Линия объектларын төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү» линия объектларын урнаштыруны күздә тоткан**

ТЕРРИТОРИЯНЕ ЫЗАНЛАУ ПРОЕКТЫ

2 бүлек «Территорияне ызанлау проекты.
Текст өлеше»

**5.1/24-ПМТ-Р2**

**Бөгелмә 2025**

Теплогазпроект
ОБЩЕСТВО С ОГРАНИЧЕННОЙ ОТВЕТСТВЕННОСТЬЮ

**Заказчы – В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАЖ**

**Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, «Минзәлә урманчылыгы» ДКУ адресы буенча урнашкан «Линия объектларын төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү» линия объектларын урнаштыруны күздә тоткан**

ТЕРРИТОРИЯНЕ ЫЗАНЛАУ ПРОЕКТЫ

2 бүлек «Территорияне ызанлау проекты.
Текст өлеше»

**5.1/24-ПМТ-Р2**

**Директор Р.И. Минаҗев**

№ 18118/Вн(ТНД), 07.02.2024 ел

**Бөгелмә 2025**

**Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, «Минзәлә урманчылыгы» ДКУ чикләрендә урнашкан линия объектларын төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү**

| Бүлек № | Билгесе | Атамасы | Иск. |
|---|---|---|---|
| 1 | 5.1/24-ПМТ-Р1 | 1 бүлек «Территорияне ызанлау проекты. График өлеше» | |
| 2 | 5.1/24-ПМТ-Р2 | 2 бүлек «Территорияне ызанлау проекты. Текст өлеше» | 2. Барлыкка килә торган җир кишәрлекләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге - китерелми<br>3. Ызанлау проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чикләре турында белешмәләр - китерелми |
| 3 | 5.1/24-ПМТ-Р3 | 3 бүлек «Территорияне ызанлау проектын нигезләү материаллары. График өлеше» | китерелми |
| 4 | 5.1/24-ПМТ-Р4 | 4 бүлек «Территорияне ызанлау проектын нигезләү материаллары. Аңлатма язуы» | китерелми |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

| Үзг. | Кишс | Бит | ДокNo | имз. | Дата | 5.1/24-ПМТ-Р2 | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Эшләде. | | | | | | 2 бүлек Территорияне ызанлау проекты. Текст өлеше | Стадия | Бит | Битләр |
| Отряд | | | | | | | ПМТ | 2 | |
| Н. контр. | | | | | | | **ЖЧЖ «Теплогазпроект» Бөгелмә шәһәре** | | |

## Кулланылган кыскартулар исемлеге

**КМБДР – күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестры**
**ЗУ - җир кишәрлеге**
**МСК - махсус саклана торган кишәрлек**
**т.п. - торак пункт**
**ДКУ – дәүләт казна учреждениесе**

## Эчтәлек


| | | |
|---|---|---|
| 1 | Барлыкка килә торган җир кишәрлекләре исемлеге........................................................ | 5 |
| 2 | Барлыкка килә торган җир кишәрлекләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге........................................................................................................................ | 7 |
| 3 | Ызанлау проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чикләре турында белешмәләр ........................................................................................ | 8 |
| 4 | Линия объекты составында проектлана торган линия объектларын һәм капиталь төзелеш объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән барлыкка килә торган җир кишәрлекләреннән, шулай ук линия объектлары составына керә торган линия объектлары һәм капиталь төзелеш объектлары билгән гамәлдәге җир кишәрлекләреннән территорияне планлаштыру проекты нигезендә рөхсәт ителгән файдалану төре...................................................................................... | 9 |
| 5 | Территорияләрендә ызанлау проекты эшләнә торган урман кишәрлекләре турында белешмәләр......................................................................................................... | 10 |
| 6 | Урман кишәрлегенең территориаль урнашуы һәм төп характеристикалары......... | 11 |
| 6.1 | Барлыкка килә торган җир кишәрлегенең урыны, чикләре һәм мәйданы ...... ............ | 11 |
| 6.2 | Җирләрнең максатчан билгеләнеше........................................................................ | 12 |
| 6.3 | Барлыкка килә торган җир кишәрлегенең сан һәм сыйфат характеристикалары... | 13 |
| 6.4 | Җирләрне бүлү.................................................................................................... | 14 |
| 6.5 | Барлыкка килә торган җир кишәрлеге утыртмаларына характеристика................ ... | 15 |
| 6.6 | Барлыкка килә торган җир кишәрлегендә урманнардан файдалану төрләре һәм күләмнәре.................................................................................................... | 16 |
| 6.7 | Барлыкка килә торган җир кишәрлегендә урманнардан рөхсәт ителгән файдалану төрләре ............................................................................................... | 16 |
| 6.8 | Барлыкка килә торган җир кишәрлегендә урманнарның махсус саклык кишәрлекләренең, махсус сакланылучы табигать территорияләренең, территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналарның булуы турында белешмәләр.................................................................................... | 18 |

| Инв.№ подл. | Имза һәм дата | Взам. инв.№ |
|---|---|---|
| | | |

# 1 Барлыкка килә торган җир кишәрлекләре исемлеге

| Барлыкка килә торган җир кишәрлекләренең шартлы номерлары | Барлыкка килә торган җир кишәрлекләренең характерлы ноктала ры номерлары | Җир кишәрлекләре барлыкка килә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары | Барлыкка килә торган җир кишәрлекләренең мәйданы, $м^2$ | Җир кишәрлекләрен барлыкка китерү ысуллары | Барлыкка килә торган җир кишәрлекләренең гомуми файдалану территориясенә кертү (кертмәү) турында белешмәләр | Урманнарның максатчан билгеләнеше, урман кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре (төрләре), урман кишәрлегенең сан һәм сыйфат характеристикалары, урман кишәрлегенең урманнарның махсус саклау кишәрлекләре чикләрендә урнашуы турында белешмәләр (территорияне ызманлау проектын әзерләү барлыкка килә торган һәм (яисә) үзгәртелә торган урман кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын билгеләү максатларында гамәлгә ашырылган очракта) | Барлыкка китерелә торган җир кишәрлекләренең шартлы номерлары, аларга карата аларны дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен резервлау һәм (яисә) тартып алу күздә тотыла торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары яисә гамәлдәге җир кишәрлекләренең элек бирелгән башка дәүләт исәп номерлары, аларның адреслары яисә урнашу урыны тасвирламасы, мондый җир кишәрлегендә урнашкан күчемсез мөлкәт объектлары исемлеге һәм адреслары (алар турында белешмәләр Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында булган очракта); | линия объекты сервитут, гавами сервитут шартларында урнаштырылырга мөмкин булган гамәлдәге җир кишәрлекләренең кадастр номерлары исемлеге, аларның адресы яисә урнашу урыны тасвирламасы, мондый җир кишәрлекләрендә урнашкан күчемсез мөлкәт объектлары исемлеге һәм адреслары (алар турында белешмәләр Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында булган очракта); | төзелә торган җир кишәрлеген җирләрнең билгеле бер категориясенә кертү турында белешмәләр (шул исәптән, әгәр җир кишәрлеге линия объектын урнаштыруга бәйле рәвештә закон нигезендә җир кишәрлеген бу категориядәге җирләр составыннан икенчесенә күчерү турында карар кабул итү кирәклегеннән башка билгеле бер җирләр категориясенә кертелергә тиеш булса) яисә җир кишәрлеген бер категориядәге җирләр составыннан икенчесенә күчерү кирәклеге турында белешмәләр; |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 16:04:000000:681 :ЗУ1 | 1<br>2<br>3<br>4 | 16:04:000000:681 | 1558 $м^2$ | башлангыч җир кишәрлеген үзгәртелгән чикләрдә саклап | Керми | 6.2, 6.3, 6.7, 6.8 пунктларын карарга | Әлеге җир кишәрлекләрен дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен резервлау һәм (яисә) тартып алу күздә тотылмый | КМБДР мәгълуматларына караганда, объектны планлаштырылган урнаштыру территориясендә гавами | Урман фонды җирләре.<br>Җир кишәрлеген бер категориядән икенчесенә күчерү зарурлыгы юк |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | калып, җир кишәрлеге н булу | | | | сервитутларның гамәлдә булу зоналары юк. | |
| 16:04:000000:706 ЗУ-1 | 1<br>2<br>3<br>4 | 16:04:000000:706 | 9499 м$^2$ | башлангыч җир кишәрлеге н үзгәртелгә н чикләрдә саклап калып, җир кишәрлеге н булу | Керми | 6.2, 6.3, 6.7, 6.8 пунктларын карарга | Әлеге җир кишәрлекләрен дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен резервлау һәм (яисә) тартып алу күздә тотылмый | КМБДР мәгълүматларына караганда, объектны планлаштырылган урнаштыру территориясендә гавами сервитутларның гамәлдә булу зоналары юк. | Урман фонды җирләре.<br>Җир кишәрлеген бер категориядән икенчесенә күчерү зарурлыгы юк |

2. **Барлыкка киле торган җир кишәрлекләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге (китерелми)**



Взам. инв. №
Имза һәм дата
Инв.№ подл.

3. **Ыҙанлау проектын әҙерләү гамәлгә ашырыла торган территория чикләре турында белешмәләр (китерелми)**

4. **Линия объекты составында проектлана торган линия объектларын һәм**

**капиталь төзелеш объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән барлыкка килә торган җир кишәрлекләреннән, шулай ук линия объектлары составына керә торган линия объектлары һәм капиталь төзелеш объектлары биләгән гамәлдәге җир кишәрлекләреннән территорияне планлаштыру проекты нигезендә рөхсәт ителгән файдалану төре**

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2020 елның 10 ноябрендәге П/0412 номерлы боерыгы нигезендә линия объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән барлыкка килә торган җир кишәрлекләреннән файдалануның рөхсәт ителгән төре – урманнардан файдалану (код 10.0).

Территорияне планлаштыру проекты Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендәге «Минзәлә урманчылыгы» ДКУ чикләрендәге урман кишәрлеге территориясен ызанлау проектын эшләүгә техник йөкләмәдә каралмаган.

## 5. Территорияләрендә чикләү проекты эшләнә торган урман кишәрлекләре турында белешмәләр

Проектлау участогы урман фонды җирләренә, атап әйткәндә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Минзәлә урманчылыгы» ДКУ Актаныш кишәрлеге урманчылыгының 203 нче кварталының 21 нче, 22 нче өлешләренә, 322 нче кварталның 1 нче өлешенә кагыла.

## 6. Урман кишәрлегенең территориаль урнашуы һәм төп характеристикалары

### 6.1 Барлыкка килә торган җир кишәрлегенең урыны, чикләре һәм мәйданы

Җирләр категориясе – урман фонды җирләре

6.1.1 таблица. Барлыкка килә торган җир кишәрлегенең чикләре һәм мәйданы

| Урманчылык атамасы | Кишәрлек урманчылыгы (хуҗалыгы) исеме | Урман квартал-лары номеры | Урман таксациясе бүлемтекләренең (аларның өлешләренең) номерлары | Мәйданы, гектар |
|---|---|---|---|---|
| «Минзәлә урманчылыгы» ДКУның Актаныш кишәрлеге урманчылыгы Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы | | | | |
| «Минзәлә урманчылыгы» ДКУ | Актаныш кишәрлеге урманчылыгы | 203 | 21 б.өлеше | 0,0253 |
| | | | 22 б.өлеше | 0,1305 |
| | | 322 | 1 б.өлеше | 0,9499 |
| | | | **Җәмгысе** | **1,1057** |

Барлыкка килә торган җир кишәрлегенең мәйданы – 1,1057 га.

## 6.2 Җирләрнең максатчан билгеләнеше

Федераль урман хуҗалыгы агентлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә урманчылыкларның санын билгеләү һәм аларның чикләрен билгеләү турында» 2008 елның 17 октябрендәге 320 номерлы боерыгы нигезендә Актаныш кишәрлеге урманчылыгы «Минзәлә урманчылыгы» ДКУ составына керә.

«Минзәлә урманчылыгы» ДКУ территориясендә урнашкан урман кишәрлеген проектлау вакытында аңа карата Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 17.01.2022 ел, № 37-осн боерыгы белән расланган Урман хуҗалыгы регламенты гамәлдә.

Күрсәтелгән урман планлаштыру документлары нигезендә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Минзәлә урманчылыгы» ДКУ Актаныш кишәрлеге урманчылыгының 203 нче кварталы (21, 22 б. өлешләре), 322 нче кварталы (1 б. өлеше) саклык урманнарына керә.

6.2.1 таблица. Барлыкка килә торган җир кишәрлеге мәйданын урманнарның максатчан билгеләнеше төрләре буенча саклау (аларның категорияләре буенча), эксплуатацияләү урманнарына бүлү

| Урманнарның максатчан билгеләнеше | Мәйданы, гектар |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Яклагыч урманнар, барлыгы | 1,1057 |
| 1) махсус саклanучы табигать территорияләрендә урнашкан урманнар; | - |
| 2) су саклау зоналарында урнашкан урманнар; | - |
| 3) табигый һәм башка объектларны саклау вазыйфасын үтәүче урманнар; | - |
| Шулардан:<br>а) эчә торган һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарының беренче һәм икенче поясларында урнашкан урманнар; | - |
| б) урманнарның саклык полосалары; | 1,1057 |
| в) урман-парк зоналарында урнашкан урманнар; | - |
| г) шәһәр урманнары; | - |
| д) дәвалау-савыктыру урыннарын һәм курортларны санитария (тау-санитария) саклау округларының беренче, икенче һәм өченче зоналарында урнашкан урманнар; | - |
| 4) кыйммәтле урманнар, барлыгы | - |
| Шулардан:<br>а) дәүләт тарафыннан саклана торган яфраклы полосалар | - |
| б) эрозиягә каршы урманнар; | - |
| в) чүл һәм ярымчүл зоналарында урнашкан урманнар; | - |
| в) урман-дала зоналарында урнашкан урманнар; | - |
| в) далаларда урнашкан урманнар; | - |
| в) тауларда урнашкан урманнар; | - |
| г) фәнни яисә тарихи әһәмияткә ия урманнар; | - |
| д) чикләвек-промысел зоналары; | - |
| е) урман җимеш утыртмалары; | - |
| ж) тасма наратлыклар; | - |
| з) су объектлары буйлап урнашкан тыелган урман полосалары; | - |
| и) урманнарның уылдык чәчү урыннарын саклау полосалары; | - |
| Эксплуатацион урманнар, барлыгы | - |
| Резерв урманнар, барлыгы | - |
| Барлыгы урманнар: | 1,1057 |

### 6.3 Барлыкка килә торган җир кишәрлегенең микъдари һәм сыйфат характеристикалары

Барлыкка килә торган җир кишәрлегенең сан һәм сыйфат характеристикалары РФ Табигый ресурслар һәм экология министрлыгының «Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан файдалану мөмкинлеге чикләнгән белешмәләрдән тыш, дәүләт урман реестрындагы белешмәләрне бирү тәртибен раслау турында» 2022 елның 26 августындагы 570 номерлы боерыгы нигезендә төзелә.

Соңгы урман корылышы вакытыннан алып бүгенге көнгә кадәр ревизия чорында урман фондында хуҗалык эшчәнлегенә, табигать факторлары йогынтысына, урман законнары үзгәрүенә, табигатьтә тикшерүләр үткәрүгә һәм урманчылык тарафыннан расланган башка үзгәрешләргә бәйле булган барлык үзгәрешләр, агымдагы үзгәрешләрне исәпкә алып, урман корылышы материалларының күчермәләре, шулай ук проект документацияләр урман төзелеше материалларына мәҗбүри кушымта булып тора.

## 6.4 Җирләрне бүлү

6.4.1 нче таблица. Барлыкка килә торган җир кишәрлеге мәйданын урман фонды җирләре категорияләре буенча бүлү

| Күрсәткечләр | Мәйданы, гектар |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1 Урман фонды җирләренең гомуми мәйданы | 1,1057 |
| 2. Урманлы җирләр, барлыгы | 0,1305 |
| 2.1 Урман үсемлекләре белән капланган, барлыгы | 0,1305 |
| 2.1.1 Шул исәптән урман культуралары | 0,1305 |
| 2.2 Урман үсемлекләре белән капланмаган, барлыгы | - |
| Шул исәптән:<br>йомылмаган урман культуралары<br>урман питомниклары, плантацияләр<br>табигый аралыклар<br>урманнарны торгызу фонды, барлыгы | - |
| Шул исәптән:<br>көекләр | - |
| һәлак булган агачлар | - |
| киселгән урыннар | - |
| ачык, ташландык урыннар | - |
| 3. Урмансыз җирләр, барлыгы | 0,9752 |
| Шул исәптән: | - |
| сөрүлекләр | - |
| печән чабу урыннары | - |
| көтүлекләр, болыннар | - |
| су | - |
| юллар, ызаннар | - |
| Коммуникация трассалары, утарлар һ.б. | 0,0253 |
| сазлар | 0,9499 |
| комлыклар | - |
| башка төрле җирләр | - |

6.4.2 таблица. Җирләрне бүлү

| Гомуми мәйдан | шул исәптән | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | урман җирләре | | | | | урмансыз җирләр | | | | |
| | Урман утыртмалары үсә торган – барлыгы | Шул исәптән урман культуралары белән капланган | Урман питомниклары; плантацияләр | Урман утыртмалары биләми торган | Җәмгысе | Юллар | Урман ызаннары | Сазлар | Башка төрле | Җәмгысе |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| 1,1057 | 0,1305 | 0,1305 | - | - | 0,1305 | - | - | 0,9499 | 0,0253 | 0,9752 |

## 6.5 Барлыкка килә торган җир кишәрлегенә утыртмаларга характеристика

6.5.1 таблица. Барлыкка килә торган җир кишәрлегенә утыртмаларга характеристика

| Кишәрлек урманчылыгы/ урман аланы (булган очракта) | Кв. № | Б. № | Утыртма составы яисә, утыртма булмаганда, урман кишәрлегенә характеристика | Агачның мәйданы (га)/запасы (мең куб.м) | Шул исәптән яшь төркемнәре буенча (га/мең куб.м) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Үрентеләр | Урта яшьле | Өлгереп килүче | Өлгергән һәм картайган |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| «Минзәлә урманчылыгы» ДКУ Актаныш кишәрлеге урманчылыгы | 203 | 21 | электр тапшыру линиясе | 0,0253/ - | - | - | - | - |
| | | 22 | урман культуралары 10С | 0,1305. 0,028 | - | 0,1305/ 0,028 | - | - |
| | 322 | 1 | саз | 0,9499/ - | - | - | - | - |
| Барлыгы | | | | **1,1057. 0,028** | | 0,1305. 0,028 | | |

6.5.2 таблица. Барлыкка килә торган җир кишәрлегендә утыртмаларның уртача таксация күрсәткечләре

| Урманнарның максатчан билгеләнеше | Урман кварталы /урман таксациясе бүлеге | Хуҗалык, өстенлек итүче токым | Утыртмаларның составы | Яше | Бонитеты | Тулылыгы | Агачның уртача запасы куб.м$^3$/ га | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | Урта яшьле | Өлгереп килүче | Өлгергән һәм картайган |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 9 | 10 | 11 |
| Саклагыч | 203/22 | Нарат | урман культуралары 10С | 46 | 1 | 0,7 | 220 | - | - |

## 6.6 Барлыкка килә торган җир кишәрлегендә урманнардан файдалану төрләре һәм күләмнәре

6.6.1 таблица. Барлыкка килә торган җир кишәрлегендә урманнардан файдалану төрләре һәм күләмнәре

| Урманнарның максатчан | Хуҗалык (ылыслы, каты | Мәйданы, (га) | Үлчәү берәмлеге | Урманнардан файдалану |
|---|---|---|---|---|

| билгеләнеше | яфраклы, йомшак яфраклы) | | | күләмнәре (урман ресурсларын алу) мең кубометр |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Саклагыч | Ылыслы | 0,1305 | мең куб.м | 0,028 |

### 6.7 Барлыкка килә торган җир кишәрлегендә урманнардан рөхсәт ителгән файдалану төрләре

Россия Федерациясе Урман кодексының 25 статьясы нигезендә урманнардан файдалануның түбәндәге төрләре булырга мөмкин:

1) агач әзерләү;
2) чәер әзерләү;
3) агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю;
4) азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыю;
5) аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру;
6) авыл хуҗалыгы алып бару;
6.1) балык тотуны гамәлгә ашыру, һәвәскәр балык тотудан тыш;
7) фәнни-тикшеренү, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру;
8) рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру;
9) урман плантацияләре төзү һәм алардан файдалану;
10) җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләре, дару үләннәре үстерү;
10.1) урман питомникларын төзү һәм алардан файдалану;
11) җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне гамәлгә ашыру, файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару;
11.1) эзләнү эшчәнлеген гамәлгә ашыру;
12) сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектларын төзү һәм эксплуатацияләү, диңгез һәм елга портларын төзү һәм киңәйтү, гидротехник корылмалар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү;
13) линия объектларын төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү;
14) урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын төзү һәм алардан файдалану;
15) дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру;
16) Урман кодексының 6 статьясындагы 2 өлеше нигезендә билгеләнгән башка төрләр.

Актаныш кишәрлеге урманчылыгының урман хуҗалыгы регламенты нигезендә «Минзәлә урманчылыгы» ДКУ территориясендә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш кишәрлеге урманчылыгының 203 кварталы (21, 22 б. өл.), 322 кварталы (1 б. өл.) чикләрендә урманнардан рөхсәт ителгән файдалануның түбәндәге төрләре билгеләнгән:

1) агач материалы әзерләү

2) чәер әзерләү;

3) агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю;

4) азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыю;

5) аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру;

6) авыл хуҗалыгы алып бару;

7) фәнни-тикшеренү, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

8) рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

9) җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләре, дару үләннәре үстерү;

10) урман питомникларын төзү һәм алардан файдалану

11) җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне гамәлгә ашыру, файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару;

12) сусаклагычлар, башка ясалма су объектлары, шулай ук гидротехник корылмалар, диңгез портлары, диңгез терминаллары, елга портлары, причаллар төзү һәм эксплуатацияләү;

13) линия объектларын төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү;

14) дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру.

Урман кишәрлеген бирүнең максаты – капиталь төзелешнең линия объектларын төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү.

### 6.8. Барлыкка килә торган җир кишәрлегендә урманнарның махсус саклана торган кишәрлекләрнең, махсус сакланылучы табигать территорияләренең, территориялардән файдалануның махсус шартлары булган зоналарның булуы турында белешмәләр

Дәүләт урман реестры белешмәләре буенча барлыкка килә торган җир кишәрлегендә махсус саклана торган урман кишәрлекләре (ОЗУ) бар. Махсус сакланылучы табигать территорияләре, территориялардән файдалануның махсус шартлары булган зоналар юк.

6.8.1 таблица. Барлыкка килә торган җир кишәрлегендә махсус саклана торган кишәрлекләр булуы турында белешмәләр

| Т/с | Кишәрлек урманчылыгы/табигый ызанның исеме (булган очракта) | Кв. № | Бүлемтек номеры | Махсус саклана торган кишәрлек төрләре, МСТТ атамасы, территориялардән файдалануның махсус шартлары булган зоналар төрләре | Гомуми мәйдан, га |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 | «Минзәлә урманчылыгы» ДКУ Актаныш кишәрлеге урманчылыгы | 203 | 22 | МСК: урмансыз киңлекләр арасында урнашкан кечкенә урман кишәрлекләре | 0,1305 |